ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423761, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2а нчы йорт.
Тел. 3-44-46
e-mail: kaz-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЗКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423761, с. Казкеево,ул.
Первомайская, дом 2а.
Тел. 3-44-46
e-mail: kaz-akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

№11 20.04.2020г.

**«Җир салымы турында» 20.11.2014 ел 17 номерлы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 20.11.2014 елның 17 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 1,5% мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләре сәнгате объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата, милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы шундый объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Кәзкәй авылы, 2а нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәислек итүче: Мансуров Г.Х.